**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**“ИШТИРӘК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ”**
**МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕК СОВЕТЫ**

**КАРАР**

"26 " сентябрь 2018 г. № 39/2

**«ИШТИРӘК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНДӘ ҖИРЛЕ РЕФЕРЕНДУМ БИЛГЕЛӘҮ ТУРЫНДА»**

---

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 20,35 статьялары, «җирле референдум турында» 2004 елның 25 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 12 Иштирәк авыл җирлеге Башкарма комитетының 2018 елның 26 сентябрендәге 16 номерлы карары белән, Иштирәк авыл җирлеге Советының 2018 елның 26 сентябрендәге 39/1 номерлы карары, Иштирәк авыл җирлеге Уставы нигезендә муниципаль берәмлек Советы,

**КАРАР КЫЛДЫ**:

1. Иштирәк авыл җирлегендә 2018 елның 18 ноябрендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум үткәрүне билгеләргә.

2. “Иштирәк авыл җирлеге” муниципаль берәмлек Советы Иштирәк авыл җирлеге башкарма комитеты белән берлектә Иштирәк авыл җирлегендә җирле референдум үткәрү турында һәм референдум сорауларын түбәндәгечә тәкъдим итте:

"Сез 2019 елда Иштирәк авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ кешегә 500 (бишйөз) сум күләмендә бер тапкыр түләүләр кертергә һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз картайган гражданнар һәм студентлар өчен бер тапкыр түләнә торган түләүне киметергә һәм әлеге категория гражданнар өчен 250 (икейөз илле) сум күләмендә билгеләргә ризамы һәм әлеге сумма түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдереләчәкбез:

- Иштирәк авылында янгын сүндерү депосы проектлау һәм төзү;
- Иштирәк авылының Үзәк урамында юллар төзекләндерү;
- Аулаш авылының Үзәк урамында урам яктырткычларын ремонтлау.”

3. Референдум әзерләү һәм үткәрүне референдум комиссиясенә йөкләргә:

- муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе (Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы территориаль сайлау комиссиясе) ;

- Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иштирәк авыл җирлеге участок сайлаукомиссияләре.
4. Җирле референдум үткәрү белән бәйле чыгымнарныИштирәк авыл җирлеге бюджеты хисабына тормышка ашырга.
5.Әлеге карарны «Якты юл» («Светлый путь») газетасында бастырырга.
6. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсмисайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсмипорталында игъланитәргә.
7. Әлеге карар басылыпчыккан көненнән үзкөченәкерә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Советы рәисе Г.С. Гарифуллина